БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» 03 2026 ел № 138

Балтач муниципаль районы составына кергән авыл жирлекләре территориясендә яшәүче гражданнар өчен һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы, Россия Федерациясе Торак кодексының 49,50,51 статьялары, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Торак урынның бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясен куллану турында» 2026 елның 2 мартындагы 124 номерлы карары нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен 2026 елда түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге чик күләмен билгеләргә:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 655 308 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 1 310 616 сум;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен - 1 965 924 сум;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 2 621 232 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 3 276 540 сум;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен - 3 931 848 сум;

1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 4 587 156 сум;

1.1.8. Сигез кешелек гаилә өчен - 5 242 464 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече күләме исәпләү буенча 20 248,97 сум тәшкил итә.

2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2027 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләре кабул ителгәнчегә кадәр, торак урыннарга мохтаҗ буларак исәпкә алу максатларында гражданнарны аз керемле дип тану буенча җаваплы вазыйфаи затларга (хезмәткәрләргә) гаилә әгъзаларының яисә ялгыз яшәүче гражданның һәр әгъзасына туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм әлеге карар белән билгеләнгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен кулланырга.

3. «Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2025 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында» Балтач районы башкарма комитетының 2025 елның 27 мартындагы 122 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов